**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 11 сентябрендәге 3858 номерлы карары**

**2024 елда Казан шәһәре территориясендә**
**авыл хуҗалыгы ярминкәләрен**
**уздыру турында**

2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 мартындагы 171 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 2 июлендәге 3783 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ярминкә операторын билгеләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре халкын авыл хуҗалыгы продукциясе белән тулырак тәэмин итү һәм шәһәр базарын халык куллана торган товарлар белән тулыландыру максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. түбәндәгеләрне билгеләргә:

1.1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетын (юридик адресы: Казан шәһәре, Кремль урамы, 1 йорт) ярминкәләрне оештыручы итеп;

1.1.2. ярминкәләрнең тибын – махсуслаштырылган (авыл хуҗалыгы) һәм универсаль;

1.1.3. ярминкәләрнең төрен тематик дип;

1.1.4. авыл хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү вакытын – 2024 елның 14 сентябреннән 29 декабренә кадәр;

1.1.5. Казан шәһәре территориясендә авыл хуҗалыгы ярминкәләрен уздыру урыннарын әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә;

1.1.6. ярминкәләрдә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук гражданнарга бирелә торган сәүдә урыннары санын әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә;

1.2. авыл хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү вакыты Казан шәһәре җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән раслана торган атна саен

уздырылучы сезонлы авыл хуҗалыгы ярминкәләрен оештыру планы нигезендә билгеләнә дип гамәлгә кертергә;

1.3. расларга:

1.3.1. Казан шәһәре территориясендә авыл хуҗалыгы ярминкәләрен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составын әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә;

1.3.2. Казан шәһәре территориясендә авыл хуҗалыгы ярминкәләре эшчәнлеген оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләренә (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» префектурасына (А.Ш.Фәезов):

1.4.1. ярминкәләрне оештыру һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы затларны билгеләргә;

1.4.2. төбәктәге һәм башка товар җитештерүчеләрне ярминкәләрдә катнашуга җәлеп итү эшен оештырырга;

1.4.3. сатылган авыл хуҗалыгы продукциясе күләме турында Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына әлеге карарга 4 номерлы кушымта белән расланган форма нигезендә атналык мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә;

1.4.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты (И.И.Сәлахетдинов) белән берлектә авыл хуҗалыгы продукциясен сату урыннарын тиешле хәлдә карап тотуны тәэмин итәргә;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына (Р.Ф.Фазылҗанов):

1.5.1. ярминкәләрне оештыру һәм уздыру эшен координацияләүне тәэмин итәргә;

1.5.2. республикадагы һәм башка товар җитештерүчеләрне ярминкәләрдә катнашуга җәлеп итү эшен оештырырга;

1.6. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 15 мартындагы 901 номерлы «2024 елда Казан шәһәре территориясендә авыл хуҗалыгы ярминкәләрен уздыру турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.7. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Л.Н.Гариповка:

2.1.1. республикадагы һәм башка товар җитештерүчеләрне ярминкәләрдә катнашуга җәлеп итү эшен оештырырга;

2.1.2. сатылган авыл хуҗалыгы продукциясе күләме турында Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына әлеге карарга 4 номерлы кушымта белән расланган форма нигезендә атналык мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә;

2.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) ярминкәләр уздыру урыннарында җәмәгать тәртибен тәэмин итәргә;

2.3. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең ЮХИДИ бүлегенә (Э.С.Садриев) җәяүлеләр һәм автомобиль транспорты хәрәкәте иминлеген, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясе төялгән автомобиль транспортының ярминкәләр уздыру урыннарына тоткарлыксыз үтүен тәэмин итәргә;

2.4. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (М.А.Патяшина) ярминкәләр уздыру урыннарында юридик һәм физик затлар тарафыннан санитария нормаларының һәм кагыйдәләренең үтәлешен контрольдә тотуны оештырырга;

2.5. «Казан шәһәренең дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә (Т.М.Галиев) ярминкәләр уздыру урыннарында юридик һәм физик затлар тарафыннан ветеринария таләпләре үтәлешен контрольдә тотуны оештырырга;

2.6. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) әлеге карарда күрсәтелгән чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 11 сентябрендәге
3858 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре территориясендә**
**авыл хуҗалыгы ярминкәләрен уздыру урыннары**

| | |
|---|---|
| Казан шәһәренең Авиатөзелеш районы | Беломорск һәм Гудованцев урамнары киселеше (102 урынга кадәр), Дементьев урамы, 7 йорт (18 урынга кадәр), Ленинград урамы, 27 йорт (70 урынга кадәр) |
| Казан шәһәренең Вахитов районы | К.Тинчурин һәм Татарстан урамнары киселеше (40 урынга кадәр) |
| Казан шәһәренең Киров районы | Краснококшайск урамы, 150/2 йорт (50 урынга кадәр), Революция урамы, 12 йорт (210 урынга кадәр), Батыршин урамы, 20 йорт (82 урынга кадәр) |
| Казан шәһәренең Яңа Савин районы | Ямашев проспекты, 71а йорт (90 урынга кадәр), Академик Лаврентьев урамы, 10 йорт (116 урынга кадәр) |
| Казан шәһәренең Идел буе районы | Җиңү проспекты, 46В йорт (27 урынга кадәр), Ю.Фучик урамы, 64 йорт, 1 корпус (25 урынга кадәр) |
| Казан шәһәренең Совет районы | Аграр урамы, 2 йорт, «“Казан” агросәнәгать паркы» акционерлык җәмгыяте (100 урынга кадәр), Липатов урамы, 7 йорт (77 урынга кадәр) |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 11 сентябрендәге
3858 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре территориясендә авыл хуҗалыгы ярминкәләрен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| И.С.Шакиров | оештыру комитеты рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Р.Ф.Фазылҗанов | оештыру комитеты рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты рәисе |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Р.Х.Шәмсетдинов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе башлыгы |
| А.И.Салихов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы |
| В.В.Жаворонков | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы |
| Р.Р.Фәтхетдинов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгы |
| А.Ш.Фәезов | Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» территориясе префекты |
| И.И.Сәлахетдинов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты рәисе |
| Л.Н.Гарипов | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Т.М.Галиев | «Казан шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы (килешү |

| | |
|---|---|
| | буенча) |
| Н.Д.Закиров | Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Э.С.Садриев | Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең ЮХИДИ бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

___________________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 11 сентябрендәге
3858 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

# Казан шәһәре территориясендә авыл хуҗалыгы ярминкәләре эшчәнлеген оештыру тәртибе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә, халык ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү максатыннан, авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималны, кыргый җимешләрне, җиләкләрне сату өчен вакытлыча уздырыла торган сезонлы авыл хуҗалыгы ярминкәләре (алга таба − ярминкәләр) эшчәнлеген оештыру тәртибен билгели.

1.2. Ярминкәләрне оештыручы – Казан шәһәре Башкарма комитеты (алга таба – Оештыручы), ул ярминкәләрне оештыра һәм уздыра.

1.3. Ярминкәләрнең операторлары – Оештыручы йөкләмәсе буенча эш итүче һәм ярминкә уздыру өчен кирәкле оештыру-техник чаралар комплексын гамәлгә ашыручы, конкурс нигезендә сайлап алынган юридик затлар яки шәхси эшмәкәрләр (алга таба – Оператор).

1.4. Ярминкәләрдә сатучылар – Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, шулай ук крестьян (фермер) хуҗалыгы, шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган яки бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүче гражданнар (алга таба − Сатучы).

1.5. Ярминкәләрнең эш тәртибе: Беломорск һәм Гудованцев урамнары киселешендә урнашкан мәйданчыктан тыш, атна саен, шимбә көннәрендә, 06.00 дән 13.00 гә кадәр.

Беломорск һәм Гудованцев урамнары киселешендә оештырыла торган ярминкәнең эш тәртибе: атна саен, якшәмбе көннәрендә, 06.00 дән 13.00 гә кадәр.

1.6. Ярминкәләрне уздыру урыннары Оештыручы тарафыннан билгеләнә.

## II. Ярминкәләр эшчәнлеген оештыру

2.1. Оештыручы (Оператор):

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе белән берлектә ярминкәләр уздыру урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны һәм булдыруны тәэмин итәргә;

- сатыла торган хайван һәм үсемлек продукциясенә ветеринария-санитария тикшерүе үткәрү өчен лабораторияләр исемлеген билгеләргә;

- ярминкәләр уза торган территорияләрдә сәүдә урыннарын урнаштыру схемасын эшләргә һәм расларга;

- ярминкәләр уза торган урыннарны чүп җыю өчен контейнерлар һәм бәдрәфләр белән җиһазландырырга;

- чүп чыгаруны һәм ярминкәләр уза торган территорияләрне җыештыруны тәэмин итәргә бурычлы.

2.2. Сатучы:

- кулланучылар хокукларын яклау, халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен һәм Россия Федерациясе законнары белән каралган башка таләпләрне үтәргә;

- товарларның аерым төрләрен сатуга карата куелган таләпләрне үтәргә;

- үлчәү чараларын (үлчәү, гер, үлчәү савытлары) кулланып товарлар сатканда сәүдә урынында метрологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килә торган үлчәү приборлары урнаштырырга;

- гамәлдәге законнар белән каралган очракларда сәүдә урынын контроль-касса техникасы белән җиһазландыруны тәэмин итәргә;

- товарларның килеп чыгышын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны, товарга теркәп бирелә торган документларны булдырырга;

- гамәлдәге законнар белән билгеләнгән таләпләр нигезендә тутырылган бәя күрсәткечләрен булдырырга;

- сатып алучыларга вакытында товарлар һәм аларны җитештерүчеләр турында ачык һәм аңлаешлы формада кирәкле дөрес мәгълүматны җиткерергә;

- билгеләнгән үрнәктәге медицина кенәгәсен булдырырга бурычлы.

Сатыла торган товарга документлар, медицина кенәгәсе ярминкәләр эшләү вакыты дәвамында Сатучыда саклана һәм Оештыручы (Оператор), тикшерү органнары, сатып алучылар таләбе буенча күрсәтелә.

Ярминкәләрдә килеп чыгышын, сыйфатын һәм кеше сәламәтлеге өчен куркынычсызлыгын раслый торган документлар белән тәэмин ителмәгән азык-төлекне сату тыела.

2.3. Сатучы әлеге нигезләмә таләпләрен бозган очракта, бу аны Оештыручының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан сәүдә урыныннан мәхрүм итү өчен нигез булып тора.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

Сәүдә итү кагыйдәләре, сәүдә эшчәнлеген регламентлаштыра торган гамәлдәге законнар белән билгеләнгән таләпләр үтәлешен контрольдә тоту үзләренә бирелгән вәкаләтләр кысаларында тикшерү һәм күзәтчелек органнары тарафыннан башкарыла.

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 11 сентябрендәге
3858 номерлы карарына
4 номерлы кушымта
(Форма)

**Сатылган авыл хуҗалыгы продукциясе күләме турында мәгълүмат**

| Ярминкәдә катнаша торган Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм районнары атамалары | Сатыла торган продукция атамасы | Үлчәү берәмлеге | Китерелгән товар саны | Иң түбән һәм иң югары бәя сум/кг, литр | Сатылган товарның гомуми суммасы (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|
| | Бәрәңге | Тонна | | | |
| | Кәбестә | Тонна | | | |
| | Кишер | Тонна | | | |
| | Чөгендер | Тонна | | | |
| | Башлы суган | Тонна | | | |
| | Яшелчә (башкалар) | Тонна | | | |
| | Сыер ите | Тонна | | | |
| | Дуңгыз ите | Тонна | | | |
| | Сарык ите | Тонна | | | |
| | Кош ите | Тонна | | | |
| | Казылык ризыклары | Мең сум | | | |
| | Йомырка | Мең данә | | | |
| | Югары сортлы он | Тонна | | | |
| | Макарон эшләнмәләре | Тонна | | | |
| | Ярмалар | Тонна | | | |
| | Карабодай | Тонна | | | |
| | Ашлык | Тонна | | | |
| | Терлек өчен катнаш азык | Тонна | | | |
| | Бал | Тонна | | | |
| | Шикәр комы | Тонна | | | |
| | Агызып сатыла торган сөт | Тонна | | | |
| | Сөт продуктлары | Тонна | | | |
| | Атланмай | Тонна | | | |
| | Сыр | Тонна | | | |
| | Икмәк, кондитер ризыклары | Мең сум | | | |
| | Көнбагыш мае | Тонна | | | |

| **Ярминкәдә катнаша торган Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм районнары атамалары** | **Сатыла торган продукция атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Китерел-гән товар саны** | **Иң түбән һәм иң югары бәя сум/кг, литр** | **Сатылган товарның гомуми суммасы (мең сум)** |
|---|---|---|---|---|---|
| | Терлек | Баш | | | |
| | Яңа тотылган балык (каклаган, тозлы) | Тонна | | | |
| | Тирес | Тонна | | | |
| | Печән | Тонна | | | |
| | Салам | Тонна | | | |
| | Башка товарлар | Мең сум | | | |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | |